ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЕРХНЕСУБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ СУБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» декабрь 2019 ел № 28

**Муниципаль хезмэт курсэту буенча административ регламентларны раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында " 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә», Балтач район башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» гы 19.04.2009 ел, № 167 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

1.1. Региональ дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү һәм бу хакта мәгълүмат бирү системасында планлаштырылган капиталь төзелеш объектын сүтү. турында хәбәрнамәләр һәм документлар урнаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1 нче кушымта);

1.2 региональ дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү һәм бу хакта мәгълүмат бирү системасында капиталь төзелеш объектын сүтү тәмамлану турында хәбәрнамәне урнаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (baltasi.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Югары Субаш авыл җирлеге башлыгы Вафин Р.Б.